**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге
423079 Яңа Ибрай авылы
Совет урамы, 5 йорт
тел. (факс) 884344- 4-27-27

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Совет Новоибрайкинского сельского
поселения Аксубаевского
муниципального района
423079 с.Новое Ибрайкино
улица Советская, д.5

# КАРАР

№ 14 2021 елның 5 марты

Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымларны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Түләүгә өметсез дип танылган вакытында түләнеп бетмәгән салымларны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны бетерү тәртибен һәм вакытында түләнеп бетмәгән салымларны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 19.08.2010 N ЯК-7-8/393@ боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымларны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә (алга таба - бурыч):

- җир салымы һәм вафат булган физик затлар мөлкәтенә салым буенча, әгәр бурыч барлыкка килү срогы өч елдан артык булса;

- җир салымы һәм вафат булган физик затлар мөлкәтенә салым буенча, мирас ачылган көннән алып 6 ай эчендә мирас алу хокукы булмаганда;

- җирле салымнар буенча, суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында билгеләнгән нигезләрдә башкарма документ түләттерүчегә башкарма документны кире кайтару турында башкарма производствоны тәмамлау хакында карар чыгарылган очракта

2. Салым түләүченең бурычларын исәптән төшерү салым органы әлеге карар һәм салым органының вакытында түләнеп бетмәгән салымлар һәм пенялар, штрафлар буенча бурычлар суммасы турындагы белешмәсе нигезендә башкарыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының финанс һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Кабиров

СОВЕТ НОВОИБРАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ